| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 июнь № 447

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә кертү тәртибен камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы редакциясенең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлү узган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналында бастырып чыгару турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы редакциясе коллегиясенең тәкъдим ителгән составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге каралары үз көчен югалтуын танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын бастырып чыгару турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 19 июль, 434 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм аерым актлары үз көчен

югалтуын тану турында» 2005 ел, 14 декабрь, 603 нче карарындагы 2 пунктның дүртенче – ундүртенче абзацлары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 13 август, 652 нче карарының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 19 июль, 434 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы редакциясе коллегиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 12 февраль, 79 нчы карары.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары норматив хокукый актларын бастырып чыгаруны тикшерүдә тотуны тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 28 июнь, 447 нче
карары белән расланды.

«Татарстан Республикасы законнары җыентыгы»
журналы редакциясе коллегиясе
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе, редакция коллегиясе рәистәше |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, редакция коллегиясе рәистәше (килешү буенча) |
| Абязова Юлия Анатольевна | «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы баш редакторы, редакция коллегиясе секретаре (килешү буенча) |

Редакция коллегиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Волкова Фәридә Рәхим кызы | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйзь улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Гафиятуллин Рәшид Фәдретдин улы | Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы (килешү буенча) |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының хокук идарәсе башлыгы |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Михеев Дмитрий Александрович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының документлар белән тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Никифоров Сергей Леонидович | «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы редакциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма директоры (килешү буенча). |

---